| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.08.2026 г.Казань № 39-4/кс-2026

Азнакай муниципаль районының Актүбә ш.т.п. «Альметьевские тепловые сети» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты Идарәсе утырышының 19.08.2026 ел, № 24-ПР беркетмәсе белән Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Азнакай муниципаль районының Актүбә ш.т.п. «Альметьевские тепловые сети» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Альметьевские тепловые сети» ҖЧҖ) өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тарифларны әлеге карарга кушымта нигезендә календарь буенча бүлеп билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән алып 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Альметьевские тепловые сети» ҖЧҖ Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге мәгълүматны ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына

тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны ачарга тиеш.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.08.2026 елның № 39-4/кс-2026
карарына кушымта

## Азнакай муниципаль районының Актүбә ш.т.п. «Альметьевские тепловые сети» ҖЧҖ өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тарифлар, календарь бүленеше белән

| № т/с | Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек, оешма исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тариф (бер компонентлы), сум / куб. м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы | | | | | | | |
| | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | |
| | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | |
| | | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк |
| | | карар үз көченә кергән көннән 19.08.2026 № 39-4/кс-2026 30.09.2026 кадәр | | | | 01.10.2026 елдан 31.12.2026 кадәр | | | |
| | Азнакай муниципаль районының Актүбә ш.т.п. | | | | | | | | |
| 1 | «Альметьевские тепловые сети» ҖЧҖ | | | | | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)* | 238,39 | 224,63 | 254,91 | 240,60 | 272,37 | 256,79 | 291,06 | 274,85 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тариф НДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 195,40 | 184,12 | 208,94 | 197,21 | 223,25 | 210,48 | 238,57 | 225,29 |

* Рәсәй Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында бүленә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
тикшереп тору һәм озата бару бүлеге